**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2020 елның 13 ноябрь** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан; дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

- Зур Нөркәй авылында бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне);
- махсуслаштырылган техниканы карап тоту - «Беларус-82.1 " тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәте өчен түләү);
- Зур Нөркәй урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урамнарны яктырту яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);
- Зур Нөркәйдә төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (үлән чабу);
- Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча җыю;
- некрологларны район «Сарман” газетасында бастырып чыгару»;
- җирлекнең торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны грейдлау;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 398 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 227 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 227 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1

1. Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл жирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2021 елда 300 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл жирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан, дүрт һәм аннан да күбрәк балалы гаиләләрдән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

– Зур Нөркәй авылында бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне);

– махсуслаштырылган техниканы карап тоту - «Беларус-82.1 " тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

– Зур Нөркәй урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урамнарны яктырту яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);

– Зур Нөркәйдә төзекләндерү буенча хезмәт күрсәтүчеләргә түләү (үлән чабу);

– Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп-чарны вакытлыча җыю;

– некрологларны район «Сарман" газетасында бастырып чыгару»;

– жирлекнең торак пункты чикләрендә жирле әһәмияттәге юлларны грейдлау.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Р.М.Гайсин